АЙЛЫК ИҖТИМАГЫЙ-ПЕДАГОГИК
ҺӘМ ФӘННИ-ӘДӘБИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАР:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХӨКҮМӘТЕ,
МӘГАРИФ МИНИСТРЛЫГЫ,
РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ

# Мәгариф

ИЮНЬ Татар телендә 1913 елның мартыннан чыга № 6 (784)

## Бу санда

**АҢ-БЕЛЕМ ВӘ ЭШ-ГАМӘЛ**

ГАЙФУЛЛИН В.
Фәннилек – милли мәгариф нигезе . . . . . 3

**ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ**

САДЫЙКОВ М.
Орфографиягә үзгәреш кирәкме? . . . . . 7
ХАТИПОВ Ф.
Якты җирлектәге һәлакәт . . . . . 9
АРСЛАНОВА С.
М. Җәлилнең «Алтынчәч» либреттосында фразеологик әйтелмәләр 13
ФӘЙЗУЛЛИН Р.
Заманга иш иҗат . . . . . 14
Олимпиада нәтиҗәләре . . . . . 17
Рәсемнәрдә калган еллар . . . . . 18

**Рус мәктәпләрендәге татар балаларына**

ГАЛИМОВА Г.
Дидактик уен – ял да, хезмәт тә . . . . . 20

**Рус балаларына – татар теле**

САЗОНОВА Н.
Г. Тукай, А. Пушкин һәм В. Ирвинг әсәрләрендә күчмә сюжетлар . . . 22
МӘГЪСҮМОВА Н.
Шаян кызлар, шук малайлар . . . . . 25

**РУССКОЕ СЛОВО**

ШАКИРОВА Л., ЮСУПОВА З.
Семантико-стилистические особенности местоимений . . . . . 29
БЛИНОВА Л.
Психологические аспекты трудностей младших школьников при обучении письму . . . . . 33
ОСИПОВСКАЯ М.
Механизмы нарушений связной речи у школьников с заиканием . . . 36
АБДУЛГАЛИМОВА Г.
Изучение темы «Корень» . . . . . 38
МАХМУТОВ М.
Министр – член-корреспондент Российской академии образования 40

**МӘКТӘПКӘЧӘ ТӘРБИЯ**

«Үги кыз» . . . . . 41
Кызыклы әлифба . . . . . 44

**БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘП**

МИЯССӘРОВА И.
Авазларны әйтүдәге кимчелекләрне төзәтү . . . . . 46
МӨХӘММӘТҖАНОВА Т.
Сөйләм телен үстерү . . . . . 49
Татар теленнән тематик план . . . . . 50
ТАҖИЕВА Р.
Сәламәтлек утравына сәяхәт . . . . . 54

ГЫЙЛЕМ ДӨНЬЯСЫНДА

Концептуальная модель национальной гимназии . . . 56
ГАЛИЕВА Н.
Балаларга белем алуда булышлык . 60
САБИРОВА Ф.
Физика һәм лирика . . . . . . . . . . 63
ГАЛИЕВА Р.
Физика дәреслекләре . . . . . . . . . 65
ГӘЛӘВЕТДИНОВ И., ГАЛИЕВА Л.
Гомуми һәм уңайлырак бүленү билгесе . . . 66
БИКМӨХӘММӘТОВ Р., ГАЗИЗОВ Ф.
Укытучының валеологик культурасы . . . 68
ЯРУЛЛИН Р., АБЗАЛОВ Р.
*Развитие двигательных способностей* . . . 69
ӘХМӘТОВА Л.
«Балаларны моңнан мәхрүм итмик...» . . . 72
Татар энциклопедиясе әдәбият турында . . . . 73

КЛАССТАН ТЫШ ЭШЛӘР

ҖӘЛӘЛИЕВ Ш.
К. Насыйри иҗатында татар халык тәрбиясе . . . . . 75
ХӘМИДУЛЛИНА Р.
Класс җитәкчеләре белән эшләүгә дифференциальле якын килү . . . . . 79
ШӘЙДУЛЛИНА Г.
*Гүзәл башкалам* . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
ГАЛИЕВА С.
Көчле шәхес булу өчен . . . . . . . . . . . . . . 83
ГАЛИЕВА Ф.
Наркомания – кешелек дошманы . . . . . . . . . 86
ӘХТӘМОВА М.
Очрашу кичәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
БЕРЕЗИНА М.
Җәйге лагерьда милли тәрбия . . . . . . . . . . . . . . 91


**Тышлыкның 1 нче битендә:** Казандагы 121 нче мәктәп мөгаллимәсе **Эльмира Гайнуллина.** Ул Казан укытучылары арасында үткәрелгән «Ел укытучысы» бәйгесендә «Иң яхшы башлангыч сыйныф укытучысы» исемен яулады. **А. Динмөхәммәтов фотосы.**


| | |
|---|---|
| **Баш мөхәррир Фәрит ШӘРИФУЛЛИН** | **43-55-82 (тел./факс)** |
| **Баш мөхәррир урынбасары М. А. Вәлиуллин** | **43-26-72 (тел./факс)** |
| **Баш мөхәррир урынбасары-** ***җаваплы сәркатип Р. Р. Бикчуров*** | **49-36-82** |
| **Бүлек мөхәррирләре:** | |
| **С. Ю. Әхмәтҗанова** | **49-36-80** |
| **А. Г. Вәлиева** | **49-36-82** |
| **М. М. Садыйков** | **49-36-80** |
| **Г. М. Шәфигуллина** | **49-36-78** |



РЕДКОЛЛЕГИЯ:

**Равил Әмирхан, Азат Әхмәдуллин, Миңнехан Әхмәтҗанов, Мәҗит Вәлиуллин, Рамил Вәлиев, Валерьян Габделхаков, Рәшит Исламшин, Марат Лотфуллин, Фәрдия Нәзирова, Флера Сафиуллина, Халидә Фәрдиева, Рамил Хәлиуллин, Камәрия Хәмидуллина, Илсур Һадиуллин, Рүзәл Юсупов, Фәүзия Юсупова**




| | |
|---|---|
| Компьютер операторлары: | |
| **Ф. Ф. Камаева** | **49-36-80** |
| **С. Г. Павлова** | **49-34-27** |
| **Г. А. Тулянкина** | **49-36-80** |
| Баш бухгалтер | |
| **С. З. Сабирҗанова** | **49-36-78** |
| Корректор | |
| **Л. А. Салихова** | **49-36-80** |

Журнал Татарстан Информация һәм матбугат министрлыгында 25 нче номерлы таныклык белән (25.05.92) теркәлде.

Материалларны күчереп басканда аларның «Мәгариф» журналыннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый.


**Хатлар өчен адрес:**
420066, Казань, ул. Декабристов, 2. Редакция журнала «Мәгариф», а/я 47



© «Мәгариф», 2001 ел



Басарга кул куелды **28.05.2001.** Форматы 70х108 $^{1}/_{16}$. Китап-журнал кәгазе. Журнал гарнитурасы. Компьютерда җыела. Офсет ысулы белән басыла. Нәшер-хисап табагы 15. Басма табагы 6. Шартлы буяу оттискы 6,3. Заказ номеры **А-218.**

**Тиражы 23081** данә.

# Физика һәм лирика

**Фәйрүзә САБИРОВА, Алабуга шәһәре**

Соңгы елларда укытуның яңадан-яңа принциплары гамәлгә кертелә бара: укытуның иҗтимагый аспектын көчәйтү (гуманитарлаштыру), аны кешелекле итү (гуманлаштыру), дифференцияләштерү, интеграцияләү һ. б. Бу яңалык-үзгәрешләр асылда укыту, тәрбияне укучының ихтыяҗларын, сәламәтлеген, кызыксынуларын исәпкә алып оештыруны күздә тота. Мисалга укыту максатларын гына алыйк. Әле кайчан гына мәктәпнең төп максаты булып укучыларны җәмгыятькә файдалы хезмәткә, тормыш алып барырга әзерлекле итү, гражданнар тәрбияләү иде. Ә хәзер укучы мәнфәгатьләренә йөз тоту шартларында шәхеснең гармоник үсүенә ирешү, барлык фәннәр буенча да үсеп килүче яшь буынны гомумкешелек кыйммәтләре белән таныштыру максаты куела. Димәк, техник фәннәрне, шул исәптән физиканы укытканда дәресләрдә музыка, сынлы сәнгать, сүз, хәтта театр әсәрләреннән файдалану максатка ярашлы булып чыга. Элек-электән «физиклар һәм лириклар» дип янәшә куеп әйтү бер дә юкка булмаган бит. Фәннең сәнгать белән, фикернең хисләр белән тыгыз мөнәсәбәтен булдыру яшь буында таныл белү сәләте, хисләр культурасы камилләшүгә, бигрәк тә уку материалына карата кызыксыну тудыруга мөмкинлекләр тудыра алыр иде.

Физиканы лирика белән бәйләп укытуга килгәндә, бу мәсьәләнең бик катлаулы икәнлеген әйтеп китәргә кирәк. Мәкаләдә күбрәк физиканы укыта башлауның беренче адымнарына мисаллар китерү белән генә чикләнергә туры килә. Исбат итеп торасы да юк бит: укучыларда фәнгә кызыксыну тәрбияләүдә нәкъ менә беренче дәресләрнең, беренче уку елының йогынтысы зур.

Менә укучыларны физикадан төүге төшенчәләр — җисем, матдә, материя — белән таныштыру дәресе бара. Иң әүвәл мөгаллим узган дәрестә үтелгәннәрне үзенчәлекле итеп кабатлап алуны кирәк таба. Шул максат белән ул **Хәсән Туфанның «Ай чыга Арча кырыннан»** шигырен сәнгатьле итеп укып чыга һәм аның нинди хисләр уятуын, күз алдында нинди күренешләр тууын сораштыра. Әйе, шигырьнең төп мәгънәсе: табигатьтәге, табигать белән кеше арасындагы камил гармониягә соклану. Мөһим лирик образ — гаҗәеп матурлыкка, табигать дөньясындагы үзара килешүчәнлеккә соклану белән бәйле хис-кичерешләр.

— Шигырьдә безне сокланырга мәҗбүр иткән нинди күренешләрне күз алдына китерәбез?

— Арча кырыннан нәкъ менә үз вакытында ай чыгу; Аккош күленә җил төшү; су өстендә көймәнең аккошлар кебек йөзүе; күлләрдән диңгез буйларына очар кошлар китүе; ай нурының куаклык эчләреннән дә үтә-үтә күл өстенә юл салуы; җилнең көймәне үз җаена борып җибәрүе һ. б.

— Мондый картиналар физикада нинди төшенчә белән йөртелә?

— Болар — физик күренешләр.

Яңа төшенчәләрне үзләштерү дә әлеге әңгәмәне дәвам итеп оештырыла: укучылар әйтеп үткән күренешләрне тасвирларга ярдәм иткән әйберләрне аерым-аерым әйтәләр: ай, аккош күле (Казан артында), ай нурлары, күл, җил, очар кошлар, *көймә, куаклык, җыр, тальян* гармун тавышы, йолдызлар, кош баласы... Аннары мөгаллим боларның да физикада махсус терминнар белән аталуын әйтеп куя.

— Нинди терминнар икән соң алар? — дип сорый ул һәм моны белү өчен дәреслек материалын игътибар белән өйрәнергә тәкъдим итә. Шуннан соң укучылар һәрберсе шигырьне эчтән генә тагын бер кат укып чыгып, анда тасвирланган предмет-күренешләрнең кайсы җисем (әйберне белдергәннәре: *ай, күл, көймә, кошлар, тальян гармун һ. б.*), кайсы матдә *(күлне тәшкил итүче су, көймәгә әверелгән агач)*, ә кайсыларын материя (аңыбыздан башка да объектив яшәгән бар нәрсә: *җилнең үз вакытында әле йомшак-ягымлы, әле каты исүе, кошларның көз җитүгә җылы якларга очуы, яшьлекнең соңы булу; алда санап үткән барлык матдәләр).*

Алга таба укытучы яки берәр укучы *Хәсән Туфанның «Кайдан алдың?»* шигырен укый, һәм бергәләп аның «Ай чыга Арча кырыннан» аермалы булган поэтик үзенчәлеге билгеләнә. Чыннан да, «Ай чыга Арча кырыннан» шигырендә предметлык, «күзгә күренүчәнлек» көчле, әйтергә кирәк, материальлек көчле. Нәкъ шул алым белән шагыйрь табигать гүзәллеген, андагы гаҗәеп камиллекне, ярашучанлыкны, яшьлекне сагыну моңы белән дә бөркеп тасвирлый һәм һәркемне дулкынландыруга ирешә. Ә «Каян алдың?» шигырендә хис-кичерешләр үзләре иҗат итеlә, тудырыла: сагыну, сөю, сагыш, күңелдәге изге хатирәләр белән бәйле әрнүләр. Шуларның һәрберсен үзенә сыйдырган-туплаганы — йөрәк. Йөрәкне шагыйрь үзе үк матдә дип атый:

> **Әй син, йөрәк —**
> **Сансыз йолдызларның —**
> **Матдәнең бер җанлы кисәге!**

— Ә кеше йөрәге үзенә сеңдергән хис-кичерешләрне, борчылу-сагышларны, өмет-шатлыкларны нинди төшенчә белән атарга икән? Бу хакта дәреслектә бер сүз дә юк!

Укытучы шул сүзләре белән уфтангандай итеп куя һәм укучыларга, иҗади уйланып, нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Фәнни төшенчәләрне берьяклы һәм беркатлы гына итеп кабул итмәскә күнектерә. Шул уңайдан укучыларны дәреслектә күрсәтелгән приборлар белән генә түгел, кеше сәламәтлеген һәм иминлеген тикшерә, саклый торганнары белән дә таныштырып китү яхшы булыр иде.

**«Сыеклыкның үзенә батырылган җисемнәргә тәэсире»** темасына үткәрелгән дәрестән дә кайбер өзекләр карыйк.

— Габдулла Тукай һәрвакыт безнең белән, — дип башлый мөгаллим дәресен. — Безгә аның балаларга атап, аларны яратып-кайгыртып язган шигырьләре аеруча якын: «Шүрәле»,

«Су анасы», «Сабыйга», «Эшкә өндәү», «Эш беткәч, уйнарга ярый» һ. б. Бүгенге дәрес материалын үзләштерергә дә Тукай ярдәм итәр кебек. Менә тагын бер шигырен, «Сөткә төшкән тычкан» исемлесен укып карыйк әле.

Әсәрне бер укучы укый да аның поэтик мәгънәсе һәм эчтәлеге ачыктан-ачык аңлашылып торганга, турыдан-туры аңа нигезләнеп, физик әңгәмә һәм күзәтүләргә күчелә: тычканга «бәладән» котылырга нинди физик күренешләр «ярдәмгә» килә? *(Тычканның тигезсез механик хәрәкәте, җисемнәрнең — тычкан, сөт — үзара тәэсир итешүе, аларның икесенең дә масса берәмлеге — грамм, килограмм, сөткә карата литр сүзен-үлчәмен куллану дөресрәк.)* Сез сорауга җавапны узган дәресләрдә өйрәнгәннәргә таянып әйттегез. Ә шигырьдә сезгә әле таныш булмаган, ягъни моңа кадәр әле үзләштерелмәгән нинди физик күренешләрне күзәттегез? *(Тычкан майга басып, табактан сикереп чыга.)* Ә ни өчен төшкәч үк сөттән чыга алмый, ә үзе язган майга баскач, батып үлүдән бик тиз котыла? Май хәзер сөттә, дөресрәге, хәзер инде әйрәндә йөзеп йөриме, әллә табак төбендә торамы? Кайчан май сөт-әйрән эчендә йөзеп йөри, ә кайчан савыт төбеннән кузгалмый да? Майның йөзеп йөргән очрагы булса, тычкан аңа басып, сикереп чыга алыр идеме? Майның авырлыгы, әйрәннең күләме монда нинди дә булса роль уйнамыймы икән?!

Укучыларга сораулар ансат кына кебек тоела. Әмма үзләре бик омтылып торсалар да, төгәен генә дөрес җавап бирә алмыйлар. Дәрестә туган проблемалы ситуацияне чишәргә юл күрсәткән кебек итеп, мөгаллим бүгенге дәрестә шундый һәм шундыйрак сорауларга җавап эзләячәкләрен һәм һичшиксез табачакларын әйтә һәм тактага яңа теманы язып куя.

Тәҗрибә һәм күзәтүләр дә шул ук сөт-әйрән һәм май мисалында үткәрелә. Нәкъ менә сөт яки әйрән һәм май булу мәҗбүри түгел. Ак төстәге су — әйрән, йомры, түгәрәк формадагы каты җисем — май ролен үти ала. Сыеклыкның күләмен мөгаллим кирәгенчә я арттырып, я киметеп, майның авырлыгын үзгәртеп карый. Ә үзгәртүләр-үзгәрүләр нәтиҗәсе пыяла «табак» аша укучыларга күренеп тора.

Барлык дәресләр өчен дә поэтик үрнәк табу, шуңа нигезләнеп яңа материалны аңлату мөмкин түгелдер инде ул, әлбәттә. Шулай да өзек кенә булса да укып киту дәрес материалының укучылар күңеленә тәэсир иту көчен арттыра. Мәсәлән, чылану күренешен үткәндә **Хәсән Туфанның «Россияннар»** шигырен укып, аның ике строфасын гына яттан сәнгатьле укып, ассызыклап куясың:

**Башындагы яраларыннан**
**Кан бөркелә бинтлар үтәли:**
**Куе кызыл гөлләрдән үргән**
**Венок булып аңа гүяки...**

Бишенче строфа:

**Башындагы яра бинтлары**
**Алсуланa, кызара бара;**
**Фашистларга каршы батырлык**
**Таҗ кидергән гүя Мусага?**

Механик хәрәкәт белән танышканда **Г. Тукайның «Җил»** шигырен уку артык булмас кебек: анда җилнең күп нәрсәләргә карата — җиһанга, җир йөзенә, юлларга, диңгезгә, һавага — хәрәкәтен тоемлап була.

Дәрдмәнднең түбәндәге шигырьләре тавыш дулкыннарының, аваз тирбәлешләренең төрле характердагыларын «тыңлап» карарга мөмкинлек бирер иде:

**Яз.**

**Яз булды, нисан ява пыскып, карлап,**
**Таулардан сулар ага гөрләп-шарлап.**
**Каңгылдап килде аккош белән казлар,**
**Кайнады кош, тулды күл, тулды сазлар.**
**Язларның килде җитеп якты көне,**
**Ишетелде һавада аккош өне.**
**Талпынып салмак, авыр күк йөзендә**
**Күренде килгән очып каз дөркеме.**
**Яз булды, җитте килеп хозур айлар,**
**Сайрап очты һавага бүз тургайлар.**
**Рәхәтләнеп маңгрый куй, сыер мөнгри,**
**Куанып, кешнәп уйный колынкайлар.**
**Куанып йөгрә киек иркен чүлдә,**
**Каңгылдап аккош йөзә аукан күлдә.**
**Сайраша сандугачлар, түгеп моңнар,**
**Хайваннар шатлык кыйла уңда-сулда.**

**Искәрмә.** Нисан — ләйсән яңгыр, аукан — иркен.

* * *

**Ятам кай чаклары моңлап,**
**Һаваның тынлыгын тыңлап.**
**Килә өнләр, колак чыңлап.**
**Диямен:**
**— «Ни бу? Нидәндер бу?»**
**Җавап урынында — гөрли су,**
**Тирәкле тирбәнә, шаулый!..**

— Габдулла Тукайның «Кечкенә музыкант» шигырен укыгач, укучыларга монда нинди физик күренеш булуын билгеләргә кушыла: тавышмы, әллә музыкаль тонмы? *(Быргы уйный бит.)*

. . . . . . . . . . . . . . . . . . .

**Яза шагыйрь, каләмене кулдан куймый,**
**Бер юл язып ташлый, тагын берне уйлый.**
**Шулай тыныч утырганда безнең шагыйрь,**
**Өй түрендә кемдер исә быргы уйный.**

**Тынычлыкны боза аның өче таушы,**
**Килә аннан, бер тыңласаң, мәче таушы.**
**Бер тыңласаң — чинау, бер тыңласаң —**
**Майламаган арба тәгәрмәче таушы.**

. . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Музыкаль тонга мисал итеп Тукай моңнарын, бигрәк тә аның «Әллүки»ен («Милли моңнар») алу максатка ярашлы.

Яктылык күренешләре өйрәнелгәндә укучылар белән «сәхнә бизәү» күнегүләре материалның тәпле үзләштерелүен дә, дәреснең эмоциональлеген дә тәэмин итәчәк. Мәсәлән, «Зөләйха» трагедиясенең (Гаяз Исхакый) бишенче пәрдәсе сәхнәнең төрле символик образлар, төс-яктылыклар белән бизәлүен күздә тота. Укучылар шуны приборлар ярдәмендә булдырырга тырышып карасыннар, әйдә. «Дулкын эчендә» драмасы да (Гаяз Исхакый) әле пәрдә күтәрелгәнче, алдан экранда табигать дәһшәтләре тасвир ителүен күздә тота, булса кирәк. Монда да укучылар ул диңгез дәһшәтләрен яктылыкның төрле күренешләре белән җанландыра алсалар, бик тә яхшы булыр иде.

Сәнгатьле сүз, музыка, төсләр гармониясе укучыларның хисләренә, тойгыларына йогынты ясый. Шуның нәтиҗәсендә аларның иҗади эшчәнлеге активлаша, дәресләр белән кызыксынулары, фән белән мавыгулары арта.